ISSN 0136-7110

ЧАЯН

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
THE MAGAZINE OF SATIRE AND HUMOUR



2
1999
CAJAN CHAYAN
КАЗАН

Э.ДЫШАЕВ рәсеме.

— Карчык тәмам шашты—тагын пенсия сорый!



Пушкин урамы

ХӘЙЛӘСЕЗ ДӨНЬЯ ФАЙДАСЫЗ

Бүгенге катлаулы заманда, күпләр ризык эзләп чүплектә казынганда ничек итеп исән-сау калырга? Шушы юнәлештә үз тәҗрибәсен Казан мәктәпләренең берсендә эшләүче иптәш «Чаян»га язып җибәргән. Бу иптәш бер тиен акчасыз яшәргә өйрәнгән. Хикмәт шунда ки: укытучылар өчәр ай буе эш хакларын ала алмыйча интегәләр.

СУЫНУДАН САКЛАНЫГЫЗ!

Инде ач укытучы киңәшләре белән, укучыларыбыз, сез дә таныш булыгыз.

Беренче киңәш: Мөмкин кадәр азрак хәрәкәтләнергә тырышыгыз. Иң яхшысы — ятып торырга. Ачлык игълан итүчеләр дә шулай эшли. Ятып торганда әпитит булмый икән.

Икенчесе: Сирәк-сирәк кенә сулагыз, аз сөйләшергә, гомумән, «пилмән савытыгызны», гафу — авызыгызны сирәгрәк ачарга тырышыгыз. Авызны ачтың исә селәгәй бизләре эшли башлый, ашказаны согы бүленеп чыга. Ә бу нәрсә ач карынга бә-әк начар тәэсир итә. Нәтиҗәдә ашказаны җәзбесе барлыкка килергә мөмкин, амый!


Өченчесе: Уй-фикер казанын да эшләтмәгез. Бигрәк тә хыялга ирек бирмәгез. Юкса, күз алдыгызга тәмле-тәмле ризыклар килер дә, ашказаныгыз котырып эшли башлар. Бушка эшләү укытучыга гына килешә ул, ә ашказаны белән шаярырга ярамый, агайне!

Дүртенче киңәш: Тәнегезне суынудан саклагыз. Кәбестә кебек катлы-катлы киенегез, одеал яки шәл белән төренегез. Бу сезнең тәнегез җылытуга китә торган энергиягезне артык сарыф итүдән саклар.

Ә күптән түгел мин яңа ысул уйлап таптым: «файдалы өйләнешү». Бу ысул шактый мәшәкатьле булса да, бә-әк ышанычлы. Чөнки дә файдалы өйләнү *(яки кияүгә чыгу)* укытучы булып эшләүдән коткарачак.

Минем ошбу киңәшләрем укытучыларга гына түгел, башка һөнәр ияләренә дә ярап куяр дип уйлыйм. Ә белем бирү тармагында эшләүчеләрнең исә киләсе 1 сентябрьгәчә — Бөтендөнья Белем көненә кадәр исән калуларын телим. Чөнки тере укытучы балаларга бик тә кирәк ләбаса! Кыскасы: суынмаска тырышыгыз...

Игорь ФЕДОРОВ.



А. ШУЛЬПИНОВ рәсеме.

— Гаптеринең улы — сапер! Бәрәңге казый торган чакта әтиәнисенә гел ярдәм итә!..

СӘФӘР ЧЫКТЫМ

УТЫРАБЫЗ ДА КИТӘБЕЗ...

Экзотика — маҗараны без кайчандыр Гваделупа, Токелау яки Буркина Фасо якларыннан эзли торган идек. Ә хәзер ерак йөрисе дә юк.

Күптән түгел генә мин Казаннан көнчыгыш тарафка бара торган поездга утырдым һәм удмурт иленең Камбарка төбәгенә барып җиткәнче экзотикадан арына алмадым.

Нәүмиз калды дускаем...

Юлга чыгар алдыннан Казандагы дустым белән телефоннан сөйләшеп алдык. Татарстанның Кукмара каласына эш белән җибәрәләр икән аны. Көтмәгәндә бәяләр күтәрелеп, юллык акчасының кимеп калуыннан зарланды ул.

— Иртәгә мин Кукмара вокзалы аша узам, инвестиция оештырырмын үзеңә, — дип юаттым мин дустымны һәм үзем барасы поездның, вагонның, плацкарт урынымның номерларын әйттем.

Кукмара вокзалына якыная башлауга тәрәзәгә беректем һәм тиздән берялгызы сөрәеп торган дустымны күреп алдым. Күзгә-күз карашып, сәлам биреште, елмаештык.

Әмма тепловоз, аз гына да акрынаеп тормастан, һаман алга җилдертә бирде. Һәм унбиш мең кеше гомер итә торган шәһәр артта калды... Кырык биш ел буена пассажирлар йөртүче поездларның гадиләре дә, тиз йөрешлеләре дә Кукмарада тукталып уза торды. Хәзер исә бик сирәк поездлар гына тукталгалый икән. Менә шуңа күрә дә мин япа-ялгыз басып торган дустым белән кул биреп күрешә алмадым. Ирексездән моңлы бер җыр искә төште: «Күзебез күздән китмәде — күрешергә Ходай насыйп итмәде...»

Пицца — тоз, якты йөз...

Әгерже станциясе кадәр кунакчыл станция дөньясында юктыр, билләһи! Мәгълүм булганча, кунакчыллыкның иң беренче галәмәте — ипи-тоз белән каршылау. Бу вокзалда безне ипи, пицца, тоз, сөт, сыра, аракы, тозланган нигъмәтләр, камыр ризыклары, яшелчә, җиләк-җимеш белән каршыладылар. Бәяләр Казанныкыннан кимрәк иде. Сәүдә итүчеләр поездны шулкадәр сырып алды ки, хәтта перронга чыгарлык хут калмады. Әмма тамбурдан чыкмаган килеш тә шәһәрчекнең азык-төлеккә мул яшәве, кем әйтмешли, уч төбендәгедәй аермачык күренеп торды.

Шартлаткычлык сәдака

Сарапул станциясенең перронында пассажирларга беркем дә товар тәкъдим итмәде.

«Акча кайгысы юк икән боларда, — дип уйлап куйдым мин. — Шәп яшиләр, димәк...»

Яңа гәзит алырга вокзалга кердем. Киоскерның акча кайтарып бирүе булды, алты яшьләр чамасындагы чутыр кара бер малай җиңемнән тартты. Еламый гына бу:

— Ипилек акча бирче, абзыкай... Өч көн инде ризык капканым юк...

Барлык вак акчамны учына салдым моның. Икенче ягымнан килеп, бер җирән малай икенче җиңемнән тартты. Бусы да ипилек акча сорый.

(Дәвамы 4 нче биттә.)

М. ЛАРИЧЕВ рәсеме.



В. КОСМЫЛИН рәсеме.



— Йа Ходам! Кая гына барып чыкмый безнең челноклар!

АННАН-МОННАН

Басса бакыр изәрлек ирләрнең корыч чалгыларын картлар таптап бирә.

*

Белдерү: «Сиксән яшьлек карт өеннән яшьлеген эзләп чыгып китте һәм кире кайтмады!»

*

Әкият түгел: «Булган ди бер карчык, китергәннәр ди моңа «Картлар көне»нә багышлап бәрәңге — бер капчык, аның да яртысы булган ди балчык...»

*

Тиз әйткеч: «Картлар көне»ндә елга бер бушлай мунча булганчы, «Картлар елы»нда көн дә бер мунча булсачы!

*

БДБ булгач, пикет-микетларда савыт-саба шалтырамыйча гына тормас инде...

*

Ләббәйкә, дип дан җырласак
Җир реформасына да —
Ясин чыгар көннәр килер
Солы ярмасына да!

*

Әптиктә: «Тигровая мазь» югалды! «Аю мае» сөрткәннәр, күрәсең!!!

Марс АХУНОВ.

КАЗАН.

Утырабыз да китәбез...

(Башы 3 нче биттә.)

«Әһә, — мин әйтәм, — перронда сәүдә юклыкның сәбәбе бик гади икән — Сарапулда сатар әйбер калмаган!»

Пассажирлар залында дистәләп шундый бәләкәч теләнче әвәрә килә, әле генә поезддан төшкән пассажирларга кармак сала. Малайларның берсенә бер түти батон тоттырды. Малай, ифрат та ач кеше сымак кыланып, батонга тешләрен батырды. Аннары, ишегалды түренә барып, ипине чүп әрҗәсенә ташлады. Ә мин акча биргән теге ике малай исә якындагы киосктан петарда сатып алдылар да, аны спонсор яныннан әллә ни читкә китеп тә тормастан шартлаттылар...

Тәрбия сабагы

Арияны узгач бер бәләкәч кенә авыл янында поезд туктап торырга мәҗбүр булды — каршыга килүче составны уздырып җибәрергә кирәк икән. Пассажирлар азрак булса да чирәм таптап керергә булдылар. Карасак, бер абзыкай бер түтине дөмбәсләп маташа.

— Нигә кыйныйсың аны?

Абзыкай кипкесен төртеп куйды, маңгай тирен сөртте һәм теш шыгырдатып әйтте:

— Узган атнада долларларны рубльгә алмаштырган бит чүпрәк баш! Ә доллар үсеп китте... Күпме файда керәсе иде!

Абзыкай ялгызы гына калгач, мин аны кыйммәтле чит ил сигәрите белән сыйладым һәм кызыксынасы иттем:

— Шулай да, дөресен генә әйт әле, ни өчен хатыныңа сабак бирдең?

Бер чиләк бодайны абыйсына биргән бит миңгерәү! Ә мин шул бодай эченә соңгы бер яртыны яшергән идем...

П. ШАҺРАЙ.

М. ЛАРИЧЕВ рәсеме.



Н. РАЧКОВ рәсеме.






И. НӘФИЕВ рәсеме.



В. ТИХОНОВ рәсеме.



— Кинога төшеп соңардым! Бүген мине «Хайваннар дөньясында» дигән программа өчен төшерделәр...

Е. ТАРАСОВА рәсеме.



— Нәрсә, сезнең хатыннарыгыз да читкә йөри мени инде?!.

И. КИЙКО рәсеме.



ТОКЫМЫ КОРЫГЫРЫ

ЗАТЫ КОРГЫРЫ!

Чит йортның җылысы юк

Татарстанның Спас районында коммуналь милек белән идарә итүче җирле Комитетның элеккеге рәисе һәм бүген эшсез калган 31 яшьлек ир-ат кулга алынды. Ләкин бу иптәшкә карата «фәкыйрь» дигән сүзне кулланып булмый. Чөнки ул 1997 елда ук үзенең якты киләчәген кайгыртып куйган — Болгар шәһәрендә шушы Комитет карамагындагы 180 мең тәңкәлек йортны үз исеменә теркәгән булган.

Илдән уңмаган егетләр

Зәйдән ике яшь слесарь үзләре эшли торган электростанцияне 50 мең сум «агач» акча күләмендә төп башына утырткан. Бу әфәнделәр ремонт цехы амбарындагы 245 данә турбина калагын сугып чыгып, Екатеринбург каласындагы таныш-белешләренә аткарганнар. Әгәр дә мәгәр бүтән бер «хокукый» илдә яшәгән булсалар, кем белә бит, бу ике шома егет сәүдә өлкәсендә елгыр менеджерлар булып танылырлар иде, бәлки...

Шартлаганчы тамак ялга...

Казанда яшәүче 57 яшьлек бер түти ипи, бәрәңге, хәтта май мәсьәләсендә җиңел сулап куяр инде — Идел буе районы эчке эшләр идарәсе, ике йөз грамм тротил китереп тапшырганы өчен, акчалата бүләкләде аны. Гомумән, соңгы вакытларда пенсионерларның утлы корал һәм сугыш әсбаблары китереп тапшыру очраклары күбәя бара — кесәләре таптакыр картлар өчен җан асрарлык керем ләбаса бу...

Йортсызны эшсез талый

Чаллының Комсомол районында көпә-көндез һәм урам уртасында өч кеше бер кешене очратты. Бу өчәүнең — торыр урыны, берәүнең — эшләр эш урыны юк. «Иҗтимагый яклаудан мәхрүм катлау»да исәпләнелгән бу кешеләрнең ни хакында сөйләшүе мөмкин? Акча хакында, әлбәттә. Һәм теге өчәү әлеге берәүдән 2,5 мең тәңкә акча таптырырга тотынды. Ә теге берәү исә үзенә бәйләнмәүләрен таләп итте. Ярый әле бу очрашу үлем-китем белән чикләнмәде. Атышу булды булуын. Билгесез коралдан вак ядрә белән атып, эшсез йөргән гражданинның уң ботын һәм кул чугын яраладылар һәм ул шәһәр шифаханәсенә эләкте. «Бомж»лар качып өлгерә алмады — алар якындагы милиция бүлекчәсендә вакытлыча пропискага кертелде.

Милиция җинаятьчене күтәреп йөртә...

Казанның җинаятьчеләр дөньясындагы мәшһүр «авторитеты» җеназасында хокук сагында эшләүче берничә даирә йөзгә-йөз килеп очрашырга мәҗбүр булды. Мондый очракларда төшереп алган фоторәсемнәр, кинотасмалар, якыннан торып күзәтү эшләре качып йөргән бандитларны эзәрлекләүдә һәм моңарчы билгесез булган җинаятьчел элемтәләрне ачыклауда ифрат та файда итә. Әмма бу юлы хәлләр бүтәнчәрәк килеп чыкты: «автор»ның үлеме алдыннан аңардан барлык өер әһелләре — «братва» йөз чөергән икән бит, айттерни малахай! Һәм аны соңгы юлга озатырга өердән берәү дә килмәде. Бик сирәк була торган хәл! Бу җеназага эзәрлекләүче оперативниклар гына җыелган булып чыкты. Һәм алар мәетне алып чыгышырга, зиратка кадәр озатып барырга мәҗбүр булдылар. Алланың рәхмәте, ярый әле милициянең шундый әкәмәт хәлдә калуын беркем дә сизмәде... Тәртип сагындагыларны гади кием кигән булулары һәм каушамаулары гына коткарып калды.

В. СЫЧЕНКОВ.

Д. НИКИТИН рәсеме.



— Искиткеч үтерүче дип тәкъдим иткәннәр бит сине!

Э. ДЫШАЕВ рәсеме.



— Синең кыяфәтеңне күрүгә үк карак шыр җибәрде бит!

Сәмига СӘҮБАНОВА

КАРГЫШ

Хәсән уң колак артын уң кулының имән бармагы белән кашып алды. Кычыту басылмады, көчәйде генә.

Хәсәннең коты ботына төште. Бер сәбәпсезгә, тик торганда юньле кешенең һич туктамыйча колагы кычыта мыни?!

Күз алдыннан бөтен үткәне — бүгенгесе үтте Хәсәннең. Әмма ни узган тормышында, ни хәзергесендә колак кычыттырырдай сәбәп тапмады.

Хәсәннең бер генә җире дә моңарчы сәбәпсезгә кычытмый иде.

— Һич тә булмаса йә мәгърибтә, йә мәшрикъта җир тетридер, йәки Галактикада һәлакәт бардыр! Минем колак бәла-казаны алдан белдерә торган барометрга әйләнгәндер!.. — дип сөйләнде Хәсән. — Барометрның бәла-казаның кайда икәнен миңа әйтергә генә теле юктыр? Бәлки колак артында язылгандыр да, анда ни язылганын күрә генә алмыймдыр?

Ул заманында ата коммунист булган, аннан совет властен таркатуда актив катнашып, мулла булып алган Фәндәвискә колак артын укытырга китте. Фәндәвис ифрат та дини сүзләр сөйләргә кереште:

— Иң әлек, Ходайга тапшырып, кычытуның сәбәбен туктатып торырга кирәк! Юкса, кайдадыр барган бәла-казаның җиле яисә дулкыны



монда килеп, Ходай күрсәтмәсен, бертуктаусыз кашып юкарган колак яфрагың өзелеп төшмәгәе, әлгаязы билләһи! Ә ул өзелә калса, без Хак Тәгаләнең нәфрәтенә дучар булып, гомерләребезгә иңәчәк бәла-казаларны алдан белүдән мәхрүм булачакбыз!

Тылсымчы, ниһаять, Хәсәннең колак артын карады. Бер агарды, бер кызарды, бер күгәрде!..

— Йә, тизрәк нашатыр булса да сөрт, инде, — дип ялынды Хәсән аның озак маташуына эче пошып.

Ул арада тылсымчы табиб аңына килеп өлгерде.

— Синең колак артында хатын-кызның кызык бер әгъзасы барлыкка килгән бит! — диде ул.

Хәсәннең болай да шар күзләре атылып чыга язды.

Табиб аны чәбәкләп аңына китерде.

— Кызык әгъза анда үсә аламыни?!! — дип илерде Хәсән.

— Тиешле җирең буш булмаса, колак артыннан да шәп урын юк инде! Монда борчылырлык берни юк... Җитлегү вакытында кешеләрнең генә түгел, хайваннарның да бәгъзе әгъзалары тынгысыз була. Сәбәбенә керешсәң, тынычлана ул. Хәзер ир-ат түгел, ә бәлки хатын-кыз булып чыгасың инде, тәкъсир!

— Хатынның каргышы төште микән әллә? — дип сукранды Хәсән. — Мутлыгымны яратмыйча бер генә көн минем урында булып карасаң, нишләр идең икән? — дип карганды бит һаман! Һай, бу Хәтирәне! Инде теләгәч-теләгәч, теләкнең юньлерәген теләргә булмый идемени?!! Үзенә бер теләк теләп каргыйм әле чукынчыкны: Карап карыйк, күзенә ирләрнең нинди кызык нәрсәсе үсеп чыгар икән?!

КӨПЧӘКЛЕ ЗИНДАН

Җәмәгать транспортында җилдерүче «куяннар» саны коточкыч тизлек белән арта бара. Транспорт йөртүчеләрнең кырыс карашы да, әче тавышлы кондукторларның ялварулары да бу хәлне үзгәртә алмый. Эш урынында хезмәт хакына тиешле акчаның күптән инде чыраен да күрмәгән пассажир үзенең һәрбер тиенենә чытырдап ябышкан.


Транспорт даирәсендәге закон сакчылары да бурычлы булып калмый. Кулларына контролер билеты тоткан «гайяр егет-җилкенчәкләр» пассажирлар йөртүче барлык маршрутларны да күзәтеп торалар. Яңадан-яңа чаралар уйлап табыла. Әлгәрерәк «онытучан бәндәләр»не транспорттан чыккан чакта оялталар иде. Хәзер исә, өч-дүрт таза егеттән тупланган «елгыр группа»лар, салоннарны «блокада»га алып, бичара пассажирларны «җинаять кылу урыны»нда якаларга тотынды. Мондый очракларда карышып торуның мәгънәсе юк: ике дә уйламыйча, урамга болгап ыргытулары бар...

Шулай да мин күптән түгел генә автобустан чыкканда юлыккан хәлне кешегә сөйләсәң, кеше ышанмас. Автобус килеп җитүгә, аңа ишеккә-ишек терәлеп, икенче автобус туктала. Анда — контролерлар. Пассажир үз салонынннан чыгуга ук икенче салонга эләгә һәм контроль-ревизия хезмәтендә эшләүче таза егетләрнең кочагына барып керә. Ә тозакка эләккән пассажир исә әсирлектән исән-сау котылу хакына соңгысын да чыгарып бирергә риза...

Мондый контролер-рационализаторларның шәһәр казнасын бөтәйтү өчен шулай ашкынуларын, әлбәттә, аңларга була. Әмма бүгенге заман кешеләренең таш гасыр чоры җан ияләренә генә хас ысуллар куллануын ничек аңларга?


А. ОРЕШНИКОВ,
студент.

КАЗАН.




Э. ДЫШАЕВ рәсеме.





В. БОГОРАД рәсеме.



Бервакыт мин Грузиядә АКШның юл полициясе делегациясен озатып йөрдем. СССР Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автоинспекциясе Баш идарәсендә пропаганда бүлеге башлыгы булып эшләгән чагым иде.

Делегация составында алты штатның юл полициясе башлыклары һәм референт Рамон бар иде.

Күп еллар узды. Күптән түгел генә миңа шул чакта бергә сәфәр йөргән Марк Гарт шылтыратты. Шунда ук мин аның янына — Мәскәүнең «Националь» кунакханәсенә җилдерттем. Бер-беребезне таныдык. Танымаска да мөмкин булган икән — икебезгә дә еллар тәмам бәс кундырган.

— Пенсиядә мин хәзер... Иске адресларны барлап чыкмакчы булдым, — дип шаяртты Марк Гарт. — Ә син... Рамон белән булган әкәмәтне хәтерлисеңме?

— Ничек хәтерләмим ди?! Аның иминлеге өчен җаваплы идем бит мин!..

Ул сәфәргә чыгар алдыннан генерал миңа Дәүләт куркынычсызлыгы комитетыннан килгән шифрлы хәбәрне күрсәтте. Баксаң, Рамон Үзәк разведка идарәсе хезмәткәре икән. Миңа шундый бурыч куелды: Рамон Грузиядә юньләп берни дә күрмәсен өчен барысын да эшләргә! Ул чакта Грузиядә, хәзер белгәнебезчә, яшерен объектлар күп булган икән шул.

— Мәҗлесләрдә шәраб су урынына акты. Әмма Әмрикә полицейскийлары эчү мәсьәләсендә ныклы булып чыктылар. Рамон гына һаман саен боламык булып исерде. Грузиянең ГАИ башлыгы Робинзонга шыпырт кына әйттем: Рамонга нидер кушып эчертәсез бугай, агулап үтермәгәегез, янәсе.

— Уаһ, ваһ! Шулкадәр түбәнлеккә төшергәме?!! Менә, кара!

Һәм Робинзон миңа агач касәләрне күрсәтте. Шунда гына игътибар иттем — һәркайда без бокал белән түгел, шушындый касәдән эчәбез икән. Грузиннарның йоласы шундыйдыр, дидем. Бусын дөрес чамалаганмын, ләкин ахырынача төшенеп бетмәгәнмен икән. Робинзон ике касәгә шәраб тутырды һәм миңа шуларны ике бокалга бушатырга кушты. Бер бокал мөлдерәмә тулды, ә икенчесенең төбе генә күмелде. Бер касәнең төбе бик тирән булып чыкты. Ә шәраб салгач, икесе дә тигез күренә. Эчкән чакта «Төбенә төш! Төбенә төш!» дип куәтләп торгач, Рамон безгә караганда ун тапкырга күбрәк эчәргә мәҗбүр була икән...

Пенсионерның табыны мул

Хәйләкәр грузиннарның шушы серен ачкач, Висконсин штаты пенсионеры мистер Гарт тәгәритәгәри көлде.

— Ә син хәтерлисеңме?..

...Грузиннар ул чорларда ук тау юлларына телефон үткәргәннәр иде инде. Тау үткелендә тукталгач, Робинзон кунакларга дәште:

— Кайсыгызның үз өенә шылтыратасы килә?

— Мин шылтыратам! — диде Марк Гарт. — Кызымның туган көне бүген!

Полковник Робинзон, багана янына барып, каяндыр телефон трубкасе тартып чыгарды:

— Американы тоташтырсагыз иде, Висконсин штатын! Рәхим ит, Марк. Сөйләш!

— Һеллоу, кызым! Әтиең бу. Болытлар арасыннан шылтыратам мин сиңа!

— Ә хәтерлисеңме!..

Һәм мин кунакларның мине кунакка чакырып биргән визиткаларын сәфәр хакындагы исәп-хисап документына теркәргә мәҗбүр булганлыгымны хәтергә төшердем. Ул чакта минем АКШка сәяхәт итү-итмәвем хакында хәтта уйларга да мөмкин түгел иде.

— Аның каравы син хәзер минем янга Висконсиягә килә аласың! Пенсионерның вакыты бар!


Мин үз пенсиямнең күләмен әйттем. Мистер Гарт тагын тәгәрәп көлде. Әмма, минем күзләремдәге сагышны күреп булса кирәк, тынып калды. Торып басты, ыгы-зыгы килде, нигәдер Кремльгә карап алды, кул селтәде һәм үзенең бүлмәсенә затлы ризыклардан гаҗәп мул төшке табын әзерләтте. Ә нәрсә, Әмрика Кушма Штатлары пенсионеры бит ул!


Геннадий ЦЕПУЛИН,
«Чаян»ның махсус хәбәрчесе.



Ильдус Азимов

Азимов Илдус Ильясович 1957 елда туган. 1971 елда – Казанның сонгый, ягъни, художество мәктәбен, 1976 елда – Казанның сонгый югары мәктәбен тәмамлаган. Кинохроника студиясе рәссамы. Карикатура остасы. «Чаян» белән 1984 елдан бирле хезмәттәшлек итә.







5



ЮМОР СӨЮЧЕ ДУСЛАРЫБЫЗ!

Беренче санда без Чаян рәссамнарының альбомын матбага кыла башладык һәм бу гамәл алга табан дәвам итә. Исегезгә төшерәбез: әгәр дә быел чыккан барлык саннарны да җыеп барсагыз, ике меңенче елның беренче ярты еллыгында сез кабатланмас, бай альбомга ия булачаксыз.


АҢЛАТМАЛЫ СӘЯСИ СҮЗЛЕК

Адреслы иҗтимагый яклау — ачларга икмәк исе өләшү.
Альтернатива — икейөзле уен.
Базар икътисады — товар җитештермичә генә, алыш-биреш итү.
Базарга йомшак кертү — йомшак җәеп катыга утырту.
Плюрализм — ботак чәйнәп, су эчү.
Сайлау — халык белән күз бәйләш уены.


М.ҖӘЛӘЛИЕВ.

КАЗАН.





— Хәрәмсарайда тагын штат кыскартылачак диләр ...



— Тагын туй итә мәллә болар?
— Юк ла... Соңгы киемнәрен киеп чыкканнар ...

6

АННАН–МОННАН

Кул кулга сукканда ике арада калып чебен үлә...

Аннары аның хакында: "Ул хәзер безнең арабызда юк," — диләр.

* * *

Ужымга чыгалмаган бозау шыткан бодай бөртегенә дә риза.

* * *

Сидек белән дәвалау да яңа ысул түгел — Идел суын күптән эчәбез бит.

* * *

Карчык мунчада... картының ябык кабыргаларын юамы, әллә сырлы кер тактасында кер уамы?

* * *

Кәгазь кытлыгын шуннан белэм — Примаков кәгазьсез сөйли башлады.

Марс АХУНОВ.

КАЗАН шәһәре.



— Агайнеләр! Салкын сырадан авыз итегез!



7

* * *

Ике тоткын бер камерада утыра икән. Берсе сәгать урлап, икенчесе сыер урлап суйган өчен эләккән. Жае чыккан саен берсен–берсе үртәргә тырыша икән болар. Менә, сыер карагы, тиктомалдан сорап куя:

— Сәгать ничә?

— Вакытны төгәл генә әйтә алмыйм, ләкин сизеп торам, сыер савар чак җитте бугай...

* * *

— Билл! Ни өчен әле, сез урам уртасында кан коеш оештырып маташасыз?

— Берәр сәхнәне алыр идек тә, анлык акча юк бит...

* * *

Бер мөртәт пычак күтәреп дүрт агайны куып йөри.


— Мескенләнмәгез шулчаклы, — дип җикеренә боларга бер әби, — дүртәүләшеп бер мәхлуктан качасыз!..

— Кайсыбыз артыннан куганын белмибез бит без аның!..


* * *

— Ниме, безнең участковыйга ни дип дәшәләр әле?

— Дәшмиләр. Үзе белеп килә ул!..



— Бу натурачы кызны карарга гына килгән бит ул!



— Мондый аргумент барында төкерәм мин фактларга!



Маннур САТТАРОВ

СЮРПРИЗ

Абзый, атың җиктеңме,
Җигеп ерак киттеңме?
Ярыш оештырганнардан
Гадел уен көттеңме?

Агыйделнең яры биек,
Менеп бара бер киек.
Яздылар: "Җиңеп чыкканны
Сюрприз көтә", диеп.

Әллә ул баян микән,
Приемник–мазар микән?
Әллә япон компьютеры
Иясен табар микән?

Ун дәгъвачы, бер приз,
Ни бирсәләр, шул приз.
Сюрприз түгел зур приз,
Кемгә бирү сюрприз.

И Алланың фәрманы,
Кәҗә туккән ярманы.
Сандугач дип уздырганнар
Конкурстан карганы!

— Йә, Фәрит, ятладыңмы шигырьне? Сөйләп җибәр әле!

Фәрит үзенең укытучысына — Кәримә апага ифрат та кызганып карап торды һәм җан тетрәткеч тавыш белән шигырь әйтте:

Укытучым! Сине уйлап
Тибә йөрәгем —
Син мескеннең беркемгә дә
Юк бит кирәге!

Бишенче «Б» сыйныф бүлмәсендә гайре табигый тынлык урнашты. Бераздан Кәримә апалары һушка килде һәм аптырап, моңаеп сорап куйды:

— Каян таптың моны?

Фәрит башын иде, укытучы апасына каш астыннан хәсрәтле караш ташлады.

— Үзем яздым... — дип пышылдады ул.

Укытучы Кәримә апа бу хәлне Бишенче «Б»нең сыйныф җитәкчесе Сания апага сөйләде. Сания апа Фәрит хакындагы бу хикәятне каһкаһәле елмаеп тыңлап утырды, укытучыларның бәхетсез язмышыннан зарланып алды һәм өенә кайтып китте. Әмма ул кич җитәрәк кенә бер нәрсәне исенә төшерде: мәгариф министрлыгы фронталь тикшерү уздырасы көн килеп җитә ләбаса! Димәк, укытучылар санын кыскартачаклар!

Һәм Сания апа мәктәп директоры янына йөгерде.

Александр ОСТАШЕВСКИЙ

«Кәримәкәем, сөекле апам!..»

— Ни булды, Сания ханым? — дип аптырап сорады директор.

— И Мәрьям ханым! Минем Фәрит Кәримә ханымны...

— Көчләгән мәллә?! — дип ычкындырды директор.

— Мыскыл иткән, дисәң дә була...

— Ничек? Аты-юлы беләнме?

— Юк, гомумиләштереп әйткән. Шигырьгә салган хәтта... Ә шигырьне бөтен сыйныф алдында укыган!

— Шул гына җитмәгән иде!..

Ике көннән Фәритнең бу кыланышы хакында бөтен мәктәп белә иде инде. Ашыгыч рәвештә яшерен педсовет җыйдылар. Утырышны теге шигырь яңгыраган бүлмәдә уздырдылар.

— Йә, Фәрит, ни диярсең? — дип кырыс тавыш белән мәктәп директоры сүз башлады. — Бәлки, берәр такмак белән генә җавап бирерсең безгә?!

Фәритнең мең-мең хәсрәт тулы моңсу тавышы яңгырады:

Кәримәкәем,
Сөекле апам!
Рәнҗемә, берүк —
Сине яратам!

— Нәрсә?! «Кәримәкәем?!! Кемгә шулай дип әйтәсең, малай актыгы?! — дип тузгыды директор. — Тагын мыскыл итәсеңме?!

— Беркемне дә мыскыл иткәнем юк... Нишлим соң, үлеп кызганам мин сезне — укытучыларны... Ә кемне дә булса кызгансам, үзеннән-үзе шигырь чыгара башлыйм мин. Һәрвакыт шулай.

— Димәк, син кызганган чакларыңда мыскыл итәсең?

— Юк ла... Шигырь белән генә әйтимме?

— Ә-ә-әйтеп к-кара инде, алай булгач...

Һәм тагын елардай булып Фәрит шигырь әйтте:

Сакланырсың, укытучым
Минем йөрәктә!
Кызганмый сине замана —
Гел миңгерәтә!..

Директор Фәриткә нидер әйтмәкче булган иде, әмма ул бүтән укытучылар шикелле үк, күңеле тулып, башын түбән иде...

КАЗАН шәһәре.



И. АЗИМОВ рәсеме.



А. КОСМЫЛИН рәсеме.

— Газ баллоннарын, газ пистолетларын котырып алдылар! Противогаз кимичә һичкемгә якын барышлы түгел!



— Дөресен генә әйт әле, синең гипноз сеансларыңның файдасы тияме?

— Тимәгән кая! Кергән акчага малайга — машина, кызга фатир сатып алдым.

* * *

— Безнең күрше яңа бай булмакчы.

— Ни майтармакчы инде ул?

— Хәрәмсарай сатып алырлык акча эшләмәкче.

— Ул бетәшкәнгә ни пычагыма хәрәмсарай?

— Юк. Хәрәмсарай түгел, шуны сатып алырга җитәрлек күп акча кирәк аңа!

* * *

Ике таныш бизнесмен очраша.

— Гайнетдин, нигә әле син миңа сул кулыңны бирәсең?

— Заманаларның ниндилеген беләсең! Уң кул белән кесәдәге акча янчыгын кысып тотарга туры килә...

* * *

Акционерлык җәмгыяте президенты судта җавап тота. Алданган вкладчылар арасында аның элеккеге укытучысы да бар икән.

— Сәйфетдин абый, гафу итә күрегез. Мин сезнең акчагызны алганны белмәдем бит.

— Бәлки, син бүтән акчаларның да үзеңнеке түгел икәнлеген белмәгәнсеңдер?!

* * *

— Колагың пешкән бит! Ни булды?!

— Чалбар үтүкләгәндә телефон шылтырады. Телефон төребкәсе дип, үтүкне колакка куйганмын!

— Ә бу колагыңа ни булды?

— Шылтыратып врач чакырмакчы идем шул...

* * *

Фирма хуҗасы янына ике әзмәвер килә.

— Карале, командир, сиңа урынбасар кирәкме?

— Юк.

— Ә киңәшче?

— Кирәкми!


— Алайса син безгә ике кеше өчен тиешсең!

— Ни өчен ди ул?!

— Гозереңне үтәп, урынбасарың белән киңәшчеңне теге дөньяга олактырган өчен.

РЕКЛАМА (РЕХЛАМА)

Н. РАЧКОВ рәсеме.



В. ФЕОКТИСТОВ рәсеме.



— Әбекәем, бәләкәчне маргарин мае белән син сыйладыңмы?!! Ач бүреләр хакында аңа ни сөйләрсең тагын?!!

Антон МАКУНИ

Чакырылмаган кунак

Төннең кыл уртасында ишек өстендәге кыңгырау чылтырады. Йокымнан айныша алмыйча, зарлана-зарлана дәшәм теге якка.

— Кем бар анда?

— Кемсәмәннең кече улы!

— Сау бул, алайса.

— Исәнмесез, саумысыз, нигә кәҗә саумыйсыз?

— Каян килгән этүтән?..

— Каенсардан!

— Сине чакырган кеше юк.

— Чакырып эт кенә йөри.

— Нәрсә миңа бәйләнеп торасың?

— Пока син дә ярап торасың. Ач ишегеңне!

— Ач булсаң туеп килергә иде. Сыпырт моннан. Юкса, милиция чакыртам, — дидем мин дә, аныңча кодрәтле тавышка күчеп.

— Син чакырдың — мин килдем! Милиционер ич мин!

— Ышандылар ди сиңа! Милиция бу вакытта йокы симертә!

— Ышанмасаң ыштаныңны төшереп кара! Мин — слесарь.

— Кирәкми!

— Үтмәс балта киндер чабарга кирәк була... Мин — пожарник! Дөрләп янасың ич син!

— Ә нишләп төтене күренми?

— Ач төннегеңне, күренер төтене!

— Ачканнар ди! Басканнар да качканнар ди...

— Ишегеңне ачмасаң, тәрәзәңнән керәм...

— Чебен дулап тәрәзә ваткан! Хатын! Китер карабинны, атып төшерим әле шул сакау сандугачны!

— Очтым, очтым! Ак тәүбә — кара тәүбә! Миңа гупчым кырыгынчы фатир кирәгие. Ә сезнеке унөченче генә...

— Кырыкныкы — шырык! Кырыгынчыда обрез бар.

— Ә илленчедә?

— Бурзайлары ишек төбендә.

— Алтмышынчының хәле ничек?

— Уллары тән сакчысы булып эшли.

— Җитмеш сигездә?

— Калашников автоматы...

— Очтым дигәч, очтым! Димәк, өй номерын ялгышканмын. Сезнеке сигезенче генә...

— Алдыңнан артың яхшы! Бүтән бу тирәдә балкыма! — дидем мин әңгәмәне йомгаклап. Ә хатыным «карабин» дип алып чыккан уклавын мендәр астына кыстырып куйды.

В. ТИХОНОВ рәсеме.




— «Комет» дигәнең микробларны да үтерә икән бит!

М. ЛАРИЧЕВ рәсеме.



О. ГУЦОЛА рәсеме.



КОТЫРГАН АТ ТҮБӘДӘ

Мәшһүр әкият каһарманы Карлсон белән Түбән Камадагы «Мустанг» берләшмәсе арасында нинди уртаклык һәм нинди аерма бар? Юк, бу сорауга җавап таба алмассыз! «Мустанг» атлы коммерция даирәсе сабыйларның сөекле каһарманы Карлсон шикелле үк өй түбәсендә гомер итә икән ләбаса! Мустангның бу түләүле автотукталышы «Фасция» дигән гараж кооперативының түбәсенә үк менеп кунаклаган.

Күптән түгел генә шушы кооператив идарәсе гараж түбәсенә ремонт ясарга тотынган иде. Моның өчен кооператив рәисе В. Кудрявцев гараж хуҗаларының һәммәсеннән акча каерырга тотынды. «Фасция»дә алты йөздән артык кеше машина асрый. Һәм Кудрявцев шуларның һәммәсеннән өчәр мең акча таләп итте. Әйтергә кирәк, нефтехим каласында яртылаш эшсез килеш гомер итүчеләр өчен шаккаткыч сумма бу!

Сүз дә юк, В. Кудрявцевның мондый тәкъдименә кооператив әгъзалары кискен каршы төште. Түбә дигәнең өстәгеләр аркасында зыян күрде ләбаса. Димәк, түбәне алар хисабына төзәтү хәләл булыр иде! Гараж идарәсе кооператив әгъзаларының мәнфәгатьләрен якларга тиешле сыман бит инде... Әмма идарә әгъзаләре «Мустанг»ны аяк терәп яклавы белән халыкны өнсез итте. Идарә үзенең сәер бу кыланышын бик гади генә иттереп аңлатып бирде. Янәсе, «Фасция»нең дәүләт комиссиясе кабул итеп алуы хакында документы юк...

— Бәй, алай булгач, нишләп соң шәһәр хакимияте безнең баш очына автотукталыш корып куярга рөхсәт итте? — дип тузгынды автоһәвәскәрләр. Үзләрен төп башына утыртырга маташалар дип шикләнде алар. Аларга идарә кырт кисеп җавап бирде. Янәсе, тискәре башлар, үзегезгә үз гаражларыгызны төзеп керегез! Низагчылар моннан соң ул тынычланмагач, идарә аларга ныклап ук янарга тотынды.

Кооператив әгъзаларының прокуратурага, хокук сагы комитетына мөрәҗәгать итүләре дә нәтиҗәсез калды. Зар белән килгән гараж халкына бу оешмаларда сиздерерлек иттереп әйттеләр: үзегез сайлап куйган түрәләр һәм аларның сыртына менеп атланган «Мустанг» белән үзегез аңлашыгыз!

Автоһәвәскәрләрнең хәзер бер генә өмете калды: үз мәнфәгатьләрен суд ярдәмендә яклап калу һәм хәләл акчаларын да шул ук ысул белән кайтарып алу. Бәлки суд бу шашкын «Мустанг»ны йөгәнли алыр? Хәер, «Мустанг» дигәнең кыргый ат бит ул... Җитмәсә, аңа идарә әһелләре ярдәм итә.


Ярар, кыйссабызның башына әйләнеп кайтыйк та, тагын бер сорау бирик әле.

Гараж тирәсенә менгән түрәләр белән «Мустанг» кочаклашып яши. Шулар белән Карлсон арасында нинди аерма бар? Җавап бер генә: аркасындагы җилләткечне выжылдатып оча торган Карлсон һичкемгә дә зыян китерми. Ә болар... Болар хакында һич кенә дә алай дип булмый шул.

Р. ИСМӘГЫЙЛОВ.

ТҮБӘН КАМА шәһәре.

З. ХӘКИМОВ рәсеме.



— Белешмәләрегез җитәрлек... Әмма торактан файдалану идарәсеннән фатир хакын түләвегез хакында белешмә җитенкерәми!..

ШИФАХАНӘ КӘМИТЛӘРЕ

Табибка күренгәннән соң, 59 яшьлек ир болай кызыксына:

— Духтыр иптәш, сез ничек уйлыйсыз, мин үземнең йөз яшьлек юбилеемны күрә алырмынмы икән?

— Ә сез тәмәке тартасызмы?

— Юк.

— Аракы эчәсезме?

— Юк.

— Хатын-кызлар белән шаярасызмы?

— Юк, әлбәттә.

— Алай булгач, сезгә йөзгәчә яшәүнең нинди мәгънәсе?

* * *

— Ну-с, ни булды сезгә? — дип сорый врач, үзенә күренергә килгән хатыннан.

— Әй, идән сөртә торган машинаны розеткага тоташтырган идем, кулымны ток сукты!

— Ә ни өчен аягыгызны бинт белән урадыгыз?

— Ток миңа сукты, мин аңа типтем.

* * *

Ир үзенең хатыны белән теш врачы кабинетында.

— Бер тешне суырыр өчен күпме аласыз? — дип сорый ире.

— Наркоз беләнме, әллә болай гынамы?

— Наркозсыз гына! — ди ир кеше, ныклы бер карарга килеп.

— Браво! — ди врач. — Ниһаять, бер батыр ир-ат табылды.

— Утыр, кадерлем, — ди ир хатынына, махсус креслога күрсәтеп. Янында мин булганда бернидән дә курыкма.

ТЕЛЕГРАММА

УФА
Сатирик «Һәнәк» журналы
редакциясенә
Марсель СӘЛИМОВның шәхсән үзенә



КАДЕРЛЕ
МАРСЕЛЬ ДУС!

Чаянчылар Синең 50 еллык юбилееңда — сабан туенда бөтен коллектив белән кубып биергә әзер. Моның өчен Син Казанга махсус килмичә булдыра алмассың, мөгаен.

Без Сине «Һәнәк»нең легендар баш редакторы, безнең тугры дустыбыз һәм каләмдәшебез итеп зурлыйбыз һәм хөрмәт итәбез!

Синең шәп сыйфатларны санап бетерүе дә мөмкин түгел.

Мәңге яшь егет булып яшә һәм күкрәп чәчәк ат!

Рәшит ЗӘКИЕВ,
«Чаян»ның(«Скорпион»)
баш редакторы.

Марсель СӘЛИМОВ

ПРЕЗИДЕНТКА ВИЗИТ

(Хикәя)

Кичке савымга килүем булды, шунда ук мине ферма мөдире чакыртып алды. Һәм әйтте:

— Президент администрациясеннән шылтыраттылар, Фидалия апа! ҮЗЕнең сине күрәсе килә.

Каушап төштем.

— Кем? — мин әйтәм. — Президент Рәхимовмы әллә? Әллә Ельцин үкмы?

— Һай, һай, хыялый! — дип башын чайкады мөдир. — Үзебезнең президент — Фермер хуҗалыкларыбыз ассоциациясе башлыгы. Элеккечә әйткәндә, колхоз рәисебез. Кыскасы, эшеңне бетер дә җилдер аның резиденциясенә. Искечә әйткәндә, идарәгә!

— Шушындый кар-буранны ерып барыйммы?! Алты чакрымлы юлга чыгыйммы? Син, ичмасам, Юлдыбайга әйт, үзенең кола аты белән илтеп куйсын!

— Аның үз эше бар! — дип кырт кисте мөдир. — Ничек тә барып җитәрсең әле. Син бит ирләрдән дә гайрәтлерәк хатын! Ә бармыйча ярамый — президент үзе чакыра!

Бусы да хак сүз. Сыерларымны савып бетердем дә юлга кузгалдым. Салкын җил үзәкләргә үтеп керә, күз ачкысыз буран. Аяклар көрткә бата, борын-бит зәңгәрләнеп килә. Көчкә барып җиттем.

Президентның резиденциясендә озын өстәл тулы калай банкалы сыра. Ирләр сыра чөмерә. Мине күргәч, президент җанланып куйды һәм болай диде:

— Эшлекле хезмәттәшлек программасы мәсьәләсенә яңадан тукталыйк, әфәнделәр. Рәхим итеп, таныш булыгыз һерр Швайнштейн, безнең ассоциациянең иң шәп фермеры фрау Фидалия бу! Ул социалист... пардон, капиталистик ярышта гаҗәеп уңышларга иреште!

Барысы да мине алкышларга тотынды, ә арадан берсе — чит илдән икәне күренеп тора — янымa килеп, кулымны үпте һәм болай диде:

— Гут, фрау Фидалия, зер гут! Минеке Сезгә айне гроссе бүләк бирергә тели!..

Егылып китә яздым.

— Һай, Сез нәрсә, һерр! — мин әйтәм. — Рәхмәт, әлбәттә... Ләкин мин бит, дөресен әйткәндә бөтенләй фермер түгел! Фермада эшләсәм дә...

Әмма теге мине аңламый, ул арада президентыбыз сүзгә кушылды:

— Булды, булды! Ал һәм юлыңда бул! Безнең ассоциациягә бирелгән ул тракторда үзем йөрермен. Безнең җимерек юлларда йөрер өчен ярап куяр ул! Димәк, барысы да тәртиптә. Китсәң дә ярый!

Мин әйтәм:

— Кире кайтырга ат бирегез ичмасам! Мондый яман буранда тагын алты чакрым юл үтәрлек хәлем калмады.

— Кәефемне кырма, фрау Фидалия! — дип кара коелды президент. — Чит ил кунагы алдында хур итмә! Югыйсә, сине иң алдынгы түгел икән дип уйлар да тракторны кире алыр. Ферштейн? Бар, сыпырт Ходай хакы өчен дип әйтәм!..

Һәм мин сыпырттым... Көрткә кереп баткач уйлап куйдым: «Президент һәм фрау дип аталу җиңел ул... Ә минем тормышны үзгәртеп кору күпкә кыенрак...»

А ЯК ЖЕ!

— Мәзәк сөйлә, дип аптыратасың... Иң шәп мәзәкләр — казакларның саранлыгы хакында! — диде миңа станица башлыгы Юрий Петрович Головятенко.

— Чынлапмы?

— Менә хәзер мин сиңа мәзәкне үзем тамаша итеп оештырып күрсәтәм.

— Ничек итеп?

— Әйдә, утырыйк машинага. Бер хуторда казак Хрящ түйга дип дуңгыз чәнечте...

Ярты сәгатьтән барасы җиргә барып җиттек.

— Һәй, Василий, юньле хәбәр ишеттек! Шәп сало тозлагансың икән!

Ишегалдында сыйланып утырган төшеннән Василий эре генә әйтеп куйды:

— А як же! (Шулай шул!)

— Синеке шикелле сало быел бүтән беркемдә дә булмаячак, диләр!

— А як же!

— Мин авыз итеп карамадым әле, әйткәнеңә ышанырга туры килә инде.

— А як же!

— Мин кайчан да булса авыз итәрмен итүен, кунагыбыз гына китә, нәүмиз кала...

— Бәй, керегез соң...

— Этең өрә бит! Чылбырын өзәргә маташа! Бүреңне тотып бугазлар бу, билләһи!

— А як же!

Бу мәзәк тамашадан көлеп җибәрмичә көчкә түзеп торам. Василий үзенең этен тыеп, безнең янга чыгарга уйлап та карамады, самавыр янынан кузгалмады.

Шушында нокта куярга да булыр иде. Әмма Кобанга мин мәзәк җыярга дип килмәдем. Берләшкән Милләтләр Оешмасының качаклар эшен көйләү буенча Югары Идарәсе экспертлары белән бергә килгән кеше бит әле мин!

— Ничек болай була инде бу, Юрий Петрович? Василий безне сало белән сыйламады. Ә алты мең кеше яши торган Түбәнге Бакан казаклары 3,5 мең качакны сыендырган, ач-ялангач итмәгән!

— Ә без Василийдан берни дә сорамадык бит. Кунакны кундыр, дип, турыдан әйтергә кирәк иде ул. Салосын да, горилкасын да чыгарыр иде. Ә кактырып-суктырып кына әйтеп казакны урынынннан кузгатып булмый... Казакның саранлыгы хакындагы мәзәкләр шуннан килеп чыга да инде. Краснодар ягында теркәлгән качакларның саны рәсми мәгълүматларда әйтелгән чаклысы гына да илле меңнән артып китә. Казакъстаннан качалар. Грузиядән. Халык куркып качарлык итеп кемнәр идарә итә соң аларда? Мисхәт төрекләре барысы да бездә. Аларны Үзбәкстаннан, Грузиядән куып чыгардылар, элеккеге үз җирләренә кертмәделәр. Аларга без ярдәм итәбез.

БМО экспертлары — дөньяның төрле илләреннән килгән вәкилләр Кобан казакларының чыдамлыгына шаккатты — моңа мин үзем шаһит. Качакларга ашыгыч ярдәм күрсәтү хакында карар кабул ителде, өч йөз утыз мең әмрика доллары бүлеп бирелде. Таң калдым: бу акчаның өчтән бере килешенүгә кул куюдан соң ук килеп ирешә. Безнең шахтерларга тиешле акчаның Рәсәй киңлекләрендә адашып йөрүе түгел инде бу сиңа!

Түбәнге Баклан поликлиникасының балалар бүлеге хезмәткәрләре медицина җайланмалары сатып алырга булдылар. Яңа Украин хуторы халкы башлангыч мәктәпне ремонтлау һәм киңәйтү эшенәябышты. Югыйсә, үзләренекеләр дә, качак балалар да өч сменага бүленеп укый иде.

Кырым һәм Аба районнарында дәреслекләр, компьютерлар сатып алырга тотындылар.

— Ә сало барчабызга да җитәр, — диде Головятенко.

Геннадий ЦЕПУЛИН,
«Чаян»ның махсус хәбәрчесе.
КРАСНОДАР ягы.

БАШВАТКЫЧ — КРИПТОГРАММА



Бирелгән «ачкыч»ны кулланып, сез бүрәнә ярыкларында «яшерелгән» татар халык мәкален укырсыз.

Төзеде Р. АБЗАЛОВ.

Җавабы: Ат урлангач абзар ныгытмыйлар.

Илдар ЮЗЕЕВ

БУ ӘКИЯТ ТҮГЕЛ...

Казандагы Тукай мәйданы каршындагы Су Анасы сынындагы таракны каерып алганнар.

Озак-мәңге хыял-әкияттә —
Су астында ятып кем чыдар...
Аңладылар, Казан урамына
Алып кайтты мине сынчылар.
Озын чәчләремнең таң җилендә
Тараласын, ахры, тойдылар:
Рәхмәт инде, алтын булмаса да,
Тимер тарак алга куйдылар.
Әкияти бер хозурлык сиздем
Яшьләр миңа карап узганда,
Чәчләремне тарыйм эле диеп,
Тарагыма кулны сузганда,
Урал малайлары килделәр дә
Тарагымны тартып алдылар,
Бирмәскә дип күпме тырышсам да,
Каерып һәм ватып алдылар.
Берни булмагандай, салкын гына
Узгалыйсыз миңа карап сез...
Әкият тә, урам гүзәле дә —
Мин берни дә түгел тараксыз.
Әнкәләре тәрәзәсен ачмас,
Минем арттан «Һау!»лап эт өрмәс.
Бу әкият түгел, башка дөнья,
Тарагымны беркем китермәс!
Нишләдең? Син — мине — әкиятне
Үзең иҗат иткән халык бит!
Мәйдандагы Тукай, аңла, җаным,
Зинһар тизрәк моннан алып кит!
Тузган чәчләремне күрсәтмичә,
Кара төнгә яшереп үтәм мин!
Гүзәл булу монда мөмкин түгел —
Су астына кире китәм мин —
Түзә алмасам — сезнең хыялдан да,
Әкиятегездән дә китәрмен...

Октябрь, 1997 ел.

В. ЛУГВИНЕВ рәсеме.





ЧАЯН

№ 2 (1436) 1999

Журнал укучының фикере редакция фикеренә тәңгәл килүе мөмкин.

Баш редактор
Р. ЗӘКИЕВ.

Редколлегия:
Р. АБЗАЛОВ, И. АЗИМОВ,
А. АЛЕШИН (баш рәссам)
В. БИБИШЕВ, Л. БОЧКОВА,
М. ГӘРӘЕВ, В. КОСМЫЛИН,
К. КӘРИМОВ (җаваплы секретарь),
Д. МАЛИКОВ (Зөлфәт),
С. ПРИВИНА, В. ФЕОКТИСТОВ,
Р. ХӘЛИЛУЛЛОВ,
П. ШАҺРАЙ (баш редактор урынбасары),
А. ШУЛЬПИНОВ.

Журналга Татарстан һәм Россияда, СНГ (БДБ) һәм башка илләрдә язылырга була.

УЧРЕДИТЕЛЬЛӘР:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӨКҮМӘТЕ,
ТАТАРСТАН ГАЗЕТА-ЖУРНАЛ НӘШРИЯТЫ
ҺӘМ «ЧАЯН» РЕДАКЦИЯСЕ
Журнал Татарстан республикасы Мәгълумат һәм матбугат министрлыгында теркәлде.
Теркәлү саны — 81.

ЯЗЫЛУ ХАКЫ —
БАЗАР БӘЯСЕНӘ ТИН,
ЯГЪНИ 1999 ЕЛНЫҢ
ИКЕНЧЕ ЯРТЫСЫНА
РФ КАТАЛОГЫНДА
31 СУМ 80 ТИЕН.
ТАТАРЧА «ЧАЯН»НЫҢ
ИНДЕКСЫ — 73488.
РУСЧАСЫНЫКЫ — «ЧАЯН»
(«Скорпион») — 73489.

Айга ике тапкыр татар һәм рус телләрендә чыга.

Белешмәләр өчен телефоннар:
43-50-32, 43-27-93, 49-36-16.

© «Чаян», 1999.

Татарстан газета-журнал нәшрияты типографиясендә басылды.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.
1923 елдан чыга.

Басарга кул куелды 12.03.1999 ел.
Тираж 10694. Заказ 3-46.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Офсет ысулы белән басыла.
Басма табагы 2,1. Учетн.-изд. табагы 3,01.

«Чаян»нан икәнен күрсәтмичә журнал әсәрләрен файдалану тыела.


Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2. «Чаян» редакциясе.

КОНКУРС:



“СИН ДӘ МИН, ТЕГЕ ДӘ БУ...”

В. ИЖБОЛДИН рәсеме.



А. ДЬЯКОВ рәсеме.




Г. ЕВТУХОВ рәсеме.





С. КОКАРЕВ рәсеме.



О. ТЮРЕНЬКОВ рәсеме.